Диндә көчләү юк, ләкин өндәү һәм өйрәту бар”
(Корьән Кәрим. 2:256)

# Ислам Нуры

№ 22 (650) 28 ноябрь, 2017 ел (1439, Рабигул-әүвәл) Дини-иҗтимагый газета 1995 елдан чыга 12+

## Рабигыль-әүвәл – Пәйгамбәребез туган ай



Рабигыль-әүвәл — ислам дине тарихында зур әһәмияткә ия ай, чөнки бу айда Аллаһы Тәгалә бар галәмнәргә рәхмәт буларак кешелекнең өстенлеген һәм мактаулы сыйфатларын үзенә туплаган соңгы Пәйгамбәрен дөньяга бирә. Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең туган көне булып григориан ел исәбе буенча 571 елның Рабигыль-әүвәл аеның унберенннән уникесенә каршы төн санала.

Аллаһы Кәлам шәрифтә болай дип әйтә: “Корьән индерелгән өчен һәм аның белән гамәл кылганнары, Аның рәхмәтләре өчен шатлансыннар!” (“Юныс”сүрәсе, 58 нче аять). Башка сүзләр белән әйткәндә, Бөек Зат безгә рәхмәте өчен шатланырга куша, ә Пәйгамбәр Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм — иң зур рәхмәт, чөнки Яралтучыбыз шулай ук болай дигән: “(Ий, Мөхәммәд) Без сине бары тик рәхмәт билгесе итеп галәмдәге халыкларга күндердек” (“Әнбия” сүрәсе, 107 нче аять).

Пәйгамбәр Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең туган көне гасырлар дәвамында дөньяның төрле почмакларында билгеләп үтелә. Шулай ук Мәүлид ән-Нәби — татар халкының иң борынгы һәм тирән хөрмәткә ия бәйрәмнәренең берсе. Бу көнне безнең бабаларыбыз бергә җыелганнар, дога укыганнар, салаватлар, мөнәҗәтләр һәм касыйдәләр әйткәннәр. Моннан тыш, алар Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмне искә төшергәннәр, аның образын, тормыш юлын һәм мирасын хәтердә яңартканнар.

Аллаһы Илчесе салләллаһу галәйһи вә сәлләм җәмгыятькә татулык, тынычлык һәм рәхәтлек (гармония) алып килүче кеше була. Хәзерге дөньяда нәкъ менә шушы сыйфатлар җитеп бетми һәм моны торгызу өчен бердәнбер юл булып замандашларыбызны аның рухи мирасы белән таныштыру, аларга хакыйкый Пәйгамбәрлекнең нурын җиткерү тора.

Аллаһы Тәгалә һәрберебезне Үзенең рәхмәте белән бүләкләсә һәм Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең мөбарәк сөннәтенә ияреп яшәүләребезне насыйп итсә иде! Әмин!

**Татарстан Республикасы мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин.**

## Сораулар күп




Казанда “Россиядә вакфлар: хәзерге халәте һәм перспективалары” II Халыкара фәнни-гамәли конференциясе узды. Фәнни җыенда чит илләр һәм төбәкләрдән килгән мәртәбәле кунаклар да катнашты. Татар җәмгыятендә вакфның үсеше, тарихы, бүгенге халәте нинди? Чит илләрдә вакф системасы ни рәвешле эшли? Вакфлар социаль хәерчелек белән көрәшүгә нинди өлеш кертә ала? Вакфның Россия кысаларында үсеше мөмкинме? Конференциядә әнә шушы сорауларга җавап эзләделәр.

## Корьәнне яттан белсәң



Республикада Корьән укучылар бәйгесе үткәрелде. Корьәнне яттан белүчеләр өчен Кама буе төбәге казыяте буенча конкурс Чаллы шәһәренең “Ак мәчет” мәдрәсәсендә узган иде. Анда ирләр арасында беренче һәм икенче урыннарны Хаҗиев Равил белән Хәйбрахманов Хәлил, хатын кызлар арасында исә Хаҗиева Айсылу (11 яшь) һәм Хаҗиева Хәдичә (8 яшь) бүлештеләр. Республикакүләм бәйгедә исә Татарстанның 5 казыятеннән 17 вәкил катнашты.



Җиңүчегә дигән иң зур бүләк — хаҗга юлламаны Казаннан Азат Һадиев отты. 2 нче урынны Казаннан Закариё Борһановка тапшырдылар, 3 нче урынны Әлмәт шәһәреннән Алик Яушев алды.

## Рәхим итегез!

Татарстан республикасы мөселманнарының диния нәзарәте, Яр Чаллы мөхтәсибәте 1 декабрь көнне «Иске имля — гарәп хәрефләре, татар теле» дигән мастер класс уздыра. Бирегә Казанның “Мөхәммәдия” мәдрәсәсе өлкән мөгаллиме, Апанай мәчете имамы Әхмәт хәзрәт Сабиров, Татарстан диния нәзарәтенең дәгъвәт бүлеге җитәкчесе Нияз хәзрәт Сабиров катнашыр дип көтелә.Бирегә гарәп хәрефләрен дөрес язу, иске татар имлясы кагыйдәләре буенча мастер-класслар оештыру, дәреслекләр сату-алу күздә тотыла. Практик дәресләр өчен язу әсбаблары, дәфтәр алып килергә кирәк. Әлегә чара Яңа шәһәрнең 27/09 А адресы буенча урнашкан “Хәләл-үзәк”тә оештырыла, иртәнге сәгать 9 да башлана.



# Мәүлид кичәсе

***“Мәүлид” сүзе “туу вакыты” яисә “туган көн” дигән мәгънәне белдерә. Ислам дөньясында бу көнгә мәүлиддин-Нәби, ягъни Мөхәммәд пәйгамбәрнең туган көне диләр. Ул мөселман һиҗри айлары буенча, рабигыль-әүвәл аеның 11нче кичен 12 нче көненә бәйләгән төн уртасыннан соң Мәккә шәһәрендә туа. Нәкъ 63 ел яши һәм шул ук айның шул ук көнендә вафат була, ягъни туган һәм үлгән көннәре бер үк көннәргә туры килә.***

Пәйгамбәребез Мөхәммәд с.г.в. 571 елда туган. Атасы Габдулла, улы тумастан ике ай әүвәл вафат булса, анасы Әминә баласына 6 яшь вакытта вафат була. Мөхәммәд сигез яшенә кадәр бабасы Габделмотталлиб, 25 яшенә кадәр абзыйсы Әбү Талиб карамагында яши. 25 яшенә җиткәч, Хәдичәгә өйләнә. Бу никахтан 2 ул һәм 4 кыз туа. 40 яшенә җиткәч, пәйгамбәр була, бу шәрәфле вазыйфаны 23 ел дәвамында үтәп килә. Пәйгамбәребез с.г.в. 63 яшендә Мәдинә шәһәрендә вафат була.

Пәйгамбәребез адашу юлында булган халыкны хак иманга, хакыйкатькә өндәде. Ул заманда гарәпләр сыннарга, утка, ташларга вә тауларга табыналар, бер-берләре белән дәвамлы сугышалар, кеше үтерүне батырлыкка санайлар иде. Урлаучылар, талаучылар, хәйләкәрләр вә караклар җәмгыятьнең иң дәрәҗәле урыннарына менгәннәр иде. Зәгыйфь вә ярлыларның, мескеннәрнең, әйтерсең, яшәү хаклары юк иде. Пәйгамбәребез Мөхәммәд с.г.в. менә шундый бер милләт арасына пәйгамбәр буларак җибәрелде. Аллаһның әмер вә тыюларын кешеләргә белгертә башлагач, бары да Пәйгамбәребезгә каршы күтәрелделәр. Яһүдиләр, христианнар, потка вә утка табынучылар, сихерчеләр, хәтта Пәйгамбәребезнең кайбер якын кардәшләре дә аңа дошман булдылар. Алар Пәйгамбәребезгә вә мөселманнарга каршы искитәрлек золымнар вә усаллыклар кылды. Бу авыр хәлгә чыдый алмаган мөселманнар ике мәртәбә Хәбәшкә (Эфиопиягә) күчәргә мәҗбүр булдылар, ләкин Пәйгамбәребез һәм аның сәхабәләре бирешмәде, сабырлык күрсәтеп, ихлас гыйбадәт кылды, иҗтиһад вә дәгъват нәтиҗәсендә мөселманнарның саны арткаnnan-арта барды.

Пәйгамбәребез 13 ел буе Мәккәдә исламиятны аңлатырга тырышты. Ләкин мәккәлеләр бик үҗәт кешеләр иде, алар диннәрендәге, гореф-гадәтләрендәге үзгәрешләрне теләмәделәр. Туктаусыз эзәрлекләүләргә түзә алмаган мөселманнар 622 елда Мәдинә шәһәренә күчәләр. Пәйгамбәребез Мәдинәдә мәчетләр салдыра, иман һәм динне халыкка өйрәтү эшләренә зур әһәмият бирә. Ул Мәдинәдә 10 ел яши. Шунда Ислам дине үсеп, ныгып китә. 630 елда Пәйгамбәребез Мәккәне яулап ала. Бу надан вә азгын халык 23 елда дөньяның иң мәдәни милләте хәленә килә. Пәйгамбәребез аларны шундый рәвештә тәрбия кылды ки, алар арасында урнашкан җылылык вә дуслык кешелек тарихында беркайчан да булганы юк иде әле.

Пәйгамбәребез заманында яшәгән вә Ислам диненә иң зур хезмәт кылган кешеләргә сәхабә, ягъни Пәйгамбәребезнең иптәшләре (иярченнәре) диелде. Сәхабәләр — Коръәндә вә Пәйгамбәребез хәдисләрендә макталган кешеләрдер.

Пәйгамбәребез с.г.в. үләчәген аңлап, сәхабәләренә болай дигән: “Дөньяда өммәте арасында мәңге яшәгән һичбер пәйгамбәр юктыр. Мин дә сезнең арагыздан аерылачакмын. Сезнең белән җәннәттә, кәүсәр суы янында табышачакбыз. Җәннәттә минем белән очрашуны теләгән кешеләр кулларын вә телләрен гөнаһтан сакласыннар”.

Без Пәйгамбәребез Мөхәммәд с.г.в.не яратканыбыз өчен һәр ел аның туган көнен — Мәүлид бәйрәмен шатлык белән каршы алып үткәрәбез. Мөселманнар яши торган күп илләрдә, Пәйгамбәребезнең дөньяга килүенә ихлас шатлануны белдереп, ай дәвамында төрле чаралар уздырыла. Алар Аллаһ рәсүленең тормышын өйрәнүне, аңа күпләп салаватлар әйтүне, Коръән аятьләрен уку, догалар кылу, вәгазьләр сөйләүне үз эченә ала. Мәүлид мәҗлесләре Пәйгамбәребез узган юлны һәм аның сөннәт гамәлләрен бер-беребезгә искә төшерүне, аның күркәм әхлакый үрнәген өлге итеп алуны, рухыбызны тәрбияләү һәм ныгытуны максат итеп куя.

**(“Ислам дине нигезләре”ннән)**

## СОРАУ-ҖАВАП

**Мөхтәрәм “Ислам нуры” редакциясе!**

**Түбәндәге язмама аңлатма бирсәгез, бик рәхмәтле булыр идем.**

**Бер мәчеткә йөрүчебез нурнамә алып килде. Ул “Юлдаш” гәҗитенең 2003 ел, гыйнвар санындагы “Дин вә йола” сәхифәсендә. Кем бу нурнамәне ишетсә, укыса яки үзе белән сакласа, бик күп савапларга вәгъдә ителгән. Мәсәлән: “Ул бәндә сораусыз оҗмахның теләсә кайсы капкасыннан керер”.**

**“Нурнамәне сакламаса, күп үкенү вә хәсрәтле булыр”, - диелгән. Ул аңа көтелмәгәндә килеп керде, ә ул аны гомер буе сакларга мәҗбүр булды. Без, мәчеткә йөрүчеләр, моны аңламыйбыз. Намаз укымаучыларга шушы гына кирәк бит! Матчасына кыстырып куя да, мин оҗмахның теләсә кайсы капкасыннан керә алам, дип ята. Мондыйлар күп бит ул…**

**Салих Зиннәтов, Зәй районы Аксар авылы.**

Укучыларыбызны кызыксындырган со-рауларга шәригать белгече **Рәфыйк хәзрәт Миннәхмәтов** җавап бирә:

– Нурнамә кебек мондый догалар халык арасында байтак таралган. Янәсе, намаз укымасаң да, шушы догалар сине җәннәткә алып керер... Ләкин шәригатьтә андый әйбер юк, Коръәндә язылмаган догаларны җәннәткә кертүче дип атап йөртү иман шартына каршы килә. Бу – надан кешеләр уйлап чыгарган, яки белә торып уйлап тапкан нәрсәләр.

## МИНЕМ ФИКЕР



**Рәис хәзрәт Әхмәтов, Чаллының “Сөембикә” мәчете имам-хатыйбы:**

Шушы дөньяда яшәгән кеше үзенә матди байлыклар туплый. Һәм дөньяны ташлап киткәндә, үзеннән соң мирас калдыра. Кемдер – тиеннәр, кемдер зур байлыклар да калдырырга мөмкин. Ничек кенә бай булмасын, кеше үзе белән берни дә алып китә алмый. Байга да шундый ук кабер казыйлар, ярлыга да. Байны да гап-гади ак кәфенгә төреп күмәләр, ярлыны да... Ярлының, әйткәнемчә, бүләрлек малы калмаска мөмкин. Ә менә байның мал-мөлкәте бик еш кына нәсел-нәсәбе, балалары арасында күп тавышлар чыгуга сәбәп була. Гаҗәп бит: без, татар халкы, үзебезне мөселман дип исәпләсәк тә, күбебез намаз укымыйбыз, башка гамәлләрне дә җиренә җиткереп башкармыйбыз, һәм, билгеле инде, мирасны да Аллаһ кушканча бүлүне кирәк дип санамыйбыз.

Элек, дөрес, бу мәсьәлә гадирәк хәл ителә иде. Авылларда әти-әни янында кече малай яши, әти-әнине тәрбияләп ахирәткә озатканнан соң да байлык шунда, төп йортта кала иде. Читкә киткән балалар кайтып мал бүлешеп йөрмәде. Ул чакларда инде, дөресен әйткәндә, зурдан кубып, бүлешәбез диярлек мал да булмагандыр. Ә хәзер тормыш үзгәрде. Балаларга, чыннан да, зур гына байлыклар калырга мөмкин. Шуның өчен калган малны дөрес итеп бүлү бик мөһим. Әле минем: “Мирас малын шәригатьчә бүлдек”, - дигәннәрен ишеткәнем юк. Ә менә дөрес итеп бүлмичә, дошманлашып беткән туганнар турында инде бик күп ишеттем. Әгәр кем дә булса үзенә тиеш булмаган малны алып куллана башлый икән, бу аңа харам. Бу кеше Аллаһ каршында да гөнаһлы була, туганнар арасына да дошманлык кертә. Сүз уңаеннан: ислам динендә дә әти-әнинең балаларының берәрсенә (мохтаҗрагына яисә аларга аерым тәрбия, кадер-хөрмәт күрсәткәненә) байлыгының бер өлешен бүләк итү мөмкинлегә бар. Бүләк бүленми.

Мөселман китаплары сатыла торган кибетләрдә мирас малын бүлү тәртипләре турында язылган китаплар байтак. Мал бүлү ихтыяҗы туганда, кирәкле мәгълүматны шул китаплардан табып укырга була. Катлаулырак очракларда имамнарга мөрәҗәгать итәргә мөмкин.

Гөнаһларга төшмичә, туганлыкны боз-мыйча яшәсәк иде.

# Хәләл һәм хәрам

**Сезгә Аллаһның рәхмәте һәм сәламе булсын!**

**Аллаһ Изге Коръәндә: “Ий мөэминнәр! Без сезгә биргән пакь, хәләл ризыклардан гына ашагыз һәм Аллаһуга шөкер итегез, әгәр Аңа гыйбадәт кылучы булсагыз”(2;172), ди.**

Хәләл, пакъ ризык — Аллаһ рөхсәт иткән, тән һәм акыл өчен зыяны булмаган ризык. Хәләл ризык йөрәк өчен файдалы һәм ул изге эшләргә сәбәпче була. Хәләл ризыклар ашап үскән балалар физик яктан да, рухи яктан да сәламәт булып үсә. Әграф сүрәсендә Аллаһ болай ди: “….Күргәнебезчә, хәләл — яхшы, файдалы, ә хәрам — тыелган, начар.”

Иң элек хәрам белән хәләлнең нәрсә икәнен ачыклап үтик. “Хәрам” сүзе гарәп теленнән “тыелган, кысылган” дип тәрҗемә ителә, ягъни үтәргә ярамаган чик кебек билгеләнә. Аллаһ үзенен чиксез хикмәте белән безгә кайбер нәрсәләрне тыя. Мәсәлән, Аллаһ Коръәндә болай ди: “Ий мөэминнәр, әлбәттә, исерткеч эчемлекләр, отышлы уеннар начар эш. Сакланыгыз, бәлки отышлылардан булырсыз”. Аллаһ тыйган нәрсәләрдә кеше өчен зыян бар. Кайвакытта ул зыян кебек тоелмый. Әйтик, Аллаһ дуңгыз итен тыйган. Кем булса да әйтә ала: “Ә ни өчен дуңгыз тыела, ул бит файдалы һәм тәмле!” Әмма, әгәр дә бераз өйрәнеп, фәнни мәкаләләр белән танышсак, дунгыз итенең кеше сәламәтлеге өчен бик начар йогынты ясавында шик калмаячак.

Һәрхәлдә, Ул Аллаһ, бар нәрсәне барлыкка Китерүче, Ул безнен өчен нәрсә файдалы, нәрсә зыянлы икәнен Белүче. Без Аллаһка буйсынабыз.

Хәрамнын капма-каршысы — хәләл, яисә рөхсәт ителгән, ярый торган. Аллаһ рөхсәт иткән ашамлык, эчемлек, гамәлләр. Хәрам булмаган әйбер хәләл була. Бер нәрсәне Аллаһ тыйса, икенче нәрсәне хәләл кыла. Әйтик, Аллаһ исерткеч эчемлекләрне тыя, ләкин башка төрле эчемлекләргә тыю юк, алар хәләл санала. Аллаһ дуңгыз итен тыя, ләкин аннан тыш сыер итен, сарык итен, тавык итен, ат итен кулланып була. Аллаһ никахка хәтле мөнәсәбәтләрне тыя, ләкин Ул безгә никахлашып яшәргә рөхсәт бирә, балалар табып, аларны тәрбияләргә өнди. Аллаһ безнең өчен авырлык теләми. “Аллаһ сезнең өчен Ахирәтне тели” (аять). Шуңа күрә хәләл — ул мөселман кешесенең яшәү рәвеше. Хәләл төшенчәсе мөселман кешесенең барлык яшәү өлкәләренә тарала: хезмәт, бизнес, финанс, көнкүреш, кием-салым, кешеләр арасындагы мөнәсәбәтләр һәм башкалар. Хәләл белән хәрам төшенчәләре Коръәндә билгеләнгән, аңлашылмаган нәрсәләр булса, дин әһелләренә мөрәҗәгать итеп җавап табарга була.

Соңгы берничә елда хәләл ризыклар дөнья кибетләрендә кин колач белән тарала. Хәләл продуктларны мөселманнар гына түгел, ә христиан динен тотучылар да куллана. Хәләл ризык дигән төшенчәне анлар өчен хәрам ризык дигәнне искәртеп үтик.

Мөселманнарга түбәндәге ризыклар тыела яисә хәрам була:

— Дуңгыз ите һәм аннан ясалган ризыклар (желатин, ул күбрәк дунгыз сеңереннән ясала );

— Алкоголь (шул исәптән тәмләткеч буларак кулланганда — конфет, консервлар, тортлар);

— Кан;

— Үләксә ите;

— Бөҗәкләр, ерткыч кошлар, ерткыч хайваннар;

— Аллаһ исеме белән бугазланмаган хайван ите.

Сонгы пунктка игътибар итегез! Мәсәлән, сез тавык ите алырга уйладыгыз, тавык ите рөхсәт ителгән. Сезгә ул тавык ите шәригать кануннарын үтәп бугазланган икәнен белгән очракта гына хәләл санала. Шәригать кануннарын үтәмичә бугазланган хайванның маеннан, тиресеннән ясалган азык буягычлар һәм тәмләткечләр тыелган категориягә керә.

«Иман китереп Коръән юлы белән изге гамәлләр кылучы мөэминнәргә олы әҗер булыр дип Аллаһ вәгъдә кылды».

**Илназ хәзрәт Яхин,**
**Чаллының “Ихлас” мәчете**
**имам-хатыйбы.**

*Дөнья әдәбияты җәүһәрләреннән*

# Йөрәк бабай һәм падишаһ

*(Хикәят. Төрекчәдән Фатих Кутлу тәрҗемәсе. Дәвамы)*

ҖАҺИТ ЗАРИФОГЛУ

Карт һәрберсен биек бер агачның салкынча, рәхәт күләгәсе астына алып килде. Чатыр да яннарында гына. Утырдылар.

— Кайдан киләсез, кая барасыз болай? — дигән Йөрәк бабай. Төпченеп соравы түгел, ә болай сүз кушар өчен генә, гадәттәгечә.

— Сәүдә эшенә чыккан идек, менә йөрибез шулай, - дигән башлыклары.

Йөрәк бабай гел бу башлык кешенең генә сөйләшүен, башкаларның әдәп саклап утыруларын күзәткән.

— Бу егетләрнең башы, башлыклары синме, улым?

Бу кеше елмаеп көлгән.

— Боларның һәрберсе мине кадерле иптәшләрем. Башлык дип белсәләр, башлыклары булырмын, әмма колыбыз дисәләр, ул вакыт аларның коллары булырмын.

Барысы бергә сискәнеп, кинәт күтәрелеп басканнар һәм кулларын йөрәк өстенә куеп:

— Әстәгъфирулла, әстәгъфирулла, - дип пышылдашканнар.

— Улым, Ходай сиңа серле бер сүз әйттерде. Мин шуны аңладым, әмма теләсәң, син әйт.

— Ни аңладың, башта сине тыңлыйк әле. Зинһар, иң элек исемеңне әйт. Кем диләр сине?

— Хасан дип тә әйтәләр. Йөрәк Хасан да, Йөрәк бабай дип тә...

— Башлыклары икәнемне кайдан белеп әйтәсең?

— Белмим, шулай телемә килде. Әмма карап торам да, син үзең дә, иптәшләрең дә падишаһ булырлык кешеләр. Телегез нәзәкатьле, холкыгыз затлы, ә тәдбирегез бик нечкә.

— Нинди тәдбир ул, Йөрәк бабай?

— Бөтенегез дә чатырга аркагыз белн утырдыгыз, ягъни яшь кыз булса, ялгышып күз ташларбыз, гөнаһка керербез дип уйладыгыз. Эһ, моннан да нечкә тәдбир була аламы?

Шулай дигәннән соң Йөрәк бабай, аларга салкынча су алып килергә дип торганда, борылып болай дигән:

— Тынычлап утырыгыз. Һәр як сезнең мөлкәтегез дип белегез. Һәм өлкән яшьтәге хатыным бар, анагыз кебек булсын. Сезне дә үз балаларыбыз кебек күрер. Шуңа күрә тынычлап утырыгыз. Монда калыгыз, кунагыбыз булыгыз. Бергә ашарбыз. Без дә сезгә догада булырбыз, рәхмәт әйтербез.

— Ярар, әйбәт булыр, - дигән башлыклары. — Без болай да бик ачыккан идек инде. Тау һавасы аны тагын да арттырды.

Йөрәк бабай рөхсәт сорап читкә китте. Чатырга керде.

— Хатын, килүчеләр бик тә ачыккан, сусаганнар. Беренче итеп сусауларын басыйм әле. Турсык белән суык су алып кайтуыбыз да ярап куйды, хәзер үк илтим, - дип әйткән дә җәһәт кенә касәне, турсыкны алып, яннарына барган.

Зур касә белән тутырып биргүә, башлык яртысын бер тында, яртысының яртысын тагын бер тында, калганны да бер тын алуга эчеп бетергән.

— Абау, - дигән Йөрәк бабай, - бигрәк янган икән эчегез. Шулай да, агайлар, бу кадәр күп эчеп карыныгызны туйдырмагыз.

Калганнарына да касә белән салкын суны сузган. Күп йотып, иркен сулыш алып, бисмиллалар әйтеп, әлхәмдулиллаһ дия-дия, суны эчкәннәр. Йөрәк бабай рөхсәт сорап тагын киткән. Чатырга кергән.

— Җан юлдашым, болар бик кадерле кунакларга охшап торалар. Аллаһ безне кызганып, кунак итсеннәр дип, боларны җибәргән. Әгәр алар килмәгән булса, шул юлга чыккан ике көннән бирле, әллә Аллаһ безне яхшылыклар дәфтәреннән төшердеме, оныттымы дип эчемнән уйлый башлаган идем. Никадәр гөнаһлы бәндәләр икәнбез, ә? Аллаһны хәтерләп искә төшерү өчен я сый-хөрмәт, я бер бәла, я булмаса, мөсафир кунак тиеш булган. Аһ-ваһ безгә! Хәзер нәрсә эшлисең, килгән кунакка нәрсә әзерлисең?

— Бер казан талкан пылавы пешереп, күпме маебыз бар — барысын да салырмын. Аннан зур касәләрдә салкын әйрән, киң савытта бик тәмле катык. Кичә генә оеткан идем. Бераз икмәгебез дә бар. Вакыт булса, тагын икмәк пешерермен.

— Яхшы, - дигән Йөрәк бабай. — Бик яхшы. Вакытың табылыр.

Әмма үзе һаман нидер уйлый сыман.

— Бәем, әфәндем, нәрсә телисең, әйт.

— Кунакның мондыен беркайда да табып булмас. Һәрберсе падишаһка охшап тора. Валлаһи, болар бик кадерле кунаклар. Һәрберсен төрле ил падишаһлары дип уйлыйм. Шулай булгач, аларны болай гына сыйлау дөрес булыр микән... Ханым, Аллаһ безне кызганып җибәрде боларны, мең шөкер Ходайга. Ни әйтергә дә белмим, кыенсынам да... Әйдә, дәякәебезне чалып, боларны сыйлыйк. Ни диярсең, мәңгелек юлдашым, солтаным?

— Аһ-ваһ — диде Айшә әби. — Ваһ, минем кара язмышым. Ай, Аллаһым. Мин беттем, һәлак булдым. Аллаһ сиңа озын гомерләр бирсен. Ваһ, кара инде мине, моны ник баштарак уйламадым? Дөнья малы, дөнья хирысы минем күземне томалаган да, шуны да белмәгәнмен. Валлаһи, дәяне суеп ашатыйк бичараларны. Яхшы булыр, бик тә шәп булыр.

— Бераз курыккан идем риза булмассың дип.

— Алай булырга мөмкин түгел! Ләкин нәрсәдер борчый мине... Дәякәй булмагач, үтәсе биек тауларны уйладым да... Мин күпме генә әйбер күтәрсәм дә, нишлим, картайдым, аякларымның җегәре бетте, йөкнең күбесен сиңа күтәрергә туры килер дип куркам. Ә син һичберсен миңа бирмәссең дә... Авыр йөкләр белән нишләрсең?

— Син бер дә борчылма, - диде Йөрәк бабай. — Олуг Раббым бер җаен бирер.

Йөрәк бабай тиз генә дәякәй янына барган. Аңа яратып, мәрхәмәт белән шундый итеп караган да:

— Кил, дәякәй, - дип башыннан тоткан. Битеннән сыйпый-сыйпый аны тиешле урынга алып киткән.

Йөрәк бабай дәякәйнең башын Кәгъбәгә таба борды. Бисмилла әйтеп пычагын чыгарды. Дәякәйнең муеныңдагы тәкләрен өреп, ике якка ачты. Бисмиллаһ, Аллаһу әкбәр!

Карчыгы да шунда булып, дәякәй пычакны күрмәсен дип, куллары белән аның күзләрен каплап торды.

Дәякәй, Аллаһның аятенә туры килгән рәвештә, ян-якка егылган.

Әйдәгез, без яңадан мосафирларга кайтыйк. Кем мкән болар? Төп-төгәл җиде кеше. Киемнәрен алыштырып халык арасына чыккан падишаһ һәм вәзирләре икән болар. Бу падишаһ кичләрен утлары җемелдәп янган шәһәрдә яши, сарае да шунда имеш.

— Тирә-юньдәге авылларга, кырларга, тауларга, җәйләүләргә дә бер чыгып карыйк әле. Анда ниләр бар икән? Нинди яхшылыклар, нинди начарлыклар барганын белмәсәк, Ходай сорау алганда, ни дип җавап бирербез? — дигәннәр һәм, шулай итеп, Йөрәк бабайның чатырын күреп алганнар.

*(Дәвамы бар)*

# Әхлак сагында

Соңгы елларда халыкның гыйбадәткә тартылуы, гореф-гадәтләребезне үтәргә тырышуы күзәтелә. Шул нигездә мәчетләр салына, ислам нигезләрен аңларга тырышудан кеше намазга баса, ураза тота, хаҗ гамәлен үтәп кайта. Мәчетләребездә Коръәнне укырга өйрәтү, гарәп теле дәресләре алып барыла. Исламга тартылучылар арта. Ни гаҗәп, җан тынычлыгын югалтучылар да кимеми. Ятимнәр күбәя, урамда карт ялгызлар хәер сораша, гаиләләр таркала. Матбугат бу хакта яза, телевизор да шул турыда сөйли, зыялылар чаң суга. Яңалык түгел. Мәзәктәге кебек, былтыргы «А».

Коръән-китап бу турыда нәрсә ди соң? Пәйгамбәребез Мөхәммәд с.г.в.гә иңгән «Галәкъ» сүрәсенең беренче аятендә [илра биисми раббикә әлләзый халәл] — укы барлыкка китерүче Раббың исеме белән, диелә. Аятьтәге халәл — барлыкка китерде, иҗат итте, дип тәрҗемә ителә. Шул ук тамырдан халык, холык, күплек санда әхлак сүзләре дә ясала. Халык — кешеләр төркемен аңлатса, холык — кешенең табигате, характеры. Татар телендәге кылык сүзе холык сүзенә барып тоташа. Кылык — кылган эш, русча поступок мәгънәсендә. Әхлак сүзе барыбызга да таныш. Ул — кешеләрнең җәмгыятькә һәм бүтән кешеләргә карата мөнәсәбәтләре. Халкыбызда әхлак әдәп сүзе белән янәшә йөри. Әдәп — кешеләр белән мөгамәләдә һәм аралашуда үтәлергә тиеш булган, төптән уйланылган кагыйдәләр, яхшы гадәтләр, культура. Рус педагогы В.А.Сухомлинский: "Әгәр кеше әхлак культурасының нигезен тәшкил иткән белемнәргә ия булмаса, кешенең рухи культурасы тулы булмаячак", - ди. Аңлашылганча, рухи культура иң беренче чиратта әхлакны төзәтүдән башлана. Әхлакны ничек төзәтергә соң? Татарның Алтын Урда чоры шагыйре С.Сараи: "Коръән иңдерелүнең максаты - хуш холык тәрбияләү торыр", дип язып калдырган. Бу иң беренче чиратта, Коръәнне укыганда кеше үзенең әхлагын үзгәртү, холкын төзәтү ниятендә булырга тиешлекне күрсәтмиме?! Инде әзме-күпме Коръәнне укып караган, мәдрәсәдә гарәп телен үзләштергән кеше, әхлак төзәтү юлларын китапның үзеннән үк таба ала. Шул ук «Галәкъ» сүрәсен укуны дәвам итсәк, алдагы аятьләрдә әкрам, галләм, тәкъва сүзләрен очратабыз. Аларның тамырларына карасак, әкрам — бик юмарт, бик хөрмәтләүчән, бик затлы; галләм — бик күп белүче, зур укымышлы, күп фәннән белемле, энциклопедист; тәкъва — дин кушканнарны гына үтәүче диндар кеше, Аллаһыдан гына куркучы дигән мәгънәләрне аңлата. Аять бирелешендә әкрам Раббы сүзе белән кулланыла. Бу Аллаһның бик юмарт икәнен күрсәтә. Раббы рухы булган кеше дә шул ук сыйфатларга ия булырга тиешлекне аңлатмыймы? Әхлак төзәтү, юмартлыктан, ягъни бирүдән башланмыймы? Әхлак төзәтү күп белергә тырышуда түгелме? Әхлак төзәтү тәкъвалыкка нигезләнмиме? Коръән үзе дә бик күп сораулардан тора. Әйдәгез, Коръәнне укыганда, әхлагыбызны төзәтү турында фикерләп укыйк!



**Гөлфия Насыйбуллина,**
**тел-әдәбият, сәнгать белгече,**
**Чаллының "Ак мәчет" мәдрәсәсе шәкерте.**

*Безгә язалар*

## Укысыннар, уйлансыннар...

"Ислам нуры" газетасын кулга алып укыгач, мин дә үземнең язмамны җибәрергә уйладым. Газетада урын алып, укыган кешене уйланырга мәҗбүр итсә, туры юлга күндерсә, бик шат булыр идем.

Эшегездә уңышлар, барыгызга да саулык, тыныч тормыш, тиражыгызның көннән-көн артуын, иман нуры чәчүегезне телим.

*Исерткечне ник эчәсең,*
*Исәнлегең югалтып?*
*Яшь гомерең уза әрәм,*
*Кайтмый ул үткән вакыт.*
*Исерткечне ник эчәсең?*
*Җитә бит ул башыңа.*
*Ни җаваплар бирербез соң*
*Аллаһының каршында?*
*Исерткечне ясаучы да*
*Шайтан белән бер булыр.*
*Бар гөнаһы аңа булып,*
*Тәмуг утында торыр.*
*Исерткечне ник эчәсең? -*
*Көн дә бәйрәм, көн дә туй.*
*Айнык булсаң, уйлап кара,*
*Бозык эшне зинһар куй.*
*Атаң-анаң, әби-бабаң,*
*Балаларың да елар.*
*Синең көйне көйли-көйли,*
*Беркөн бары да туяр.*
*Янәшәңдә шайтан йөреп,*
*Кара гүренә куяр.*
*Исерткечне эчмә әле,*
*Эчмә әле тамчысын.*
*Җаның-тәнең татымасын*
*Тәмуг уты камчысын.*
*Исерткечнең юк файдасы,*
*Зарарыннан башкача.*
*Бөтен хәсрәт, сагыш уты*
*Тик шуңардан башлана.*
*Исерткечне эчмә әле,*
*Айнык булсын башкаең.*
*Дөнья – ахирәт, бәхет килер,*
*Тормыш табар үз җаен.*

**Тәзкирә Алякимова,**
**Нурлат районы**
**Түбән Норлат авылы.**

## БЕРГӘ БУЛЫЙК

*Хөрмәтле укучыларыбыз!*

*"Ислам нуры" – шактый еллар дәвамында күпләрегез яратырга өлгергән бай эчтәлекле газета. Кулдан язылган хатларыгызны алып уку, андагы теләк-тәкъдимнәрегезне, җылы сүзләрегезне ишетү безнең өчен дә бик күңелле. Ике арадагы шушы элемтәләр өзелмәсен, алдагы көннәрдә дә бергә булыйк! Газета битләрендә белдерүләр, реклама текстлары да урнаштырырга мөмкин. "Ислам нуры"на почта бүлекләрендә, Татарстан буенча гына түгел, Россиянең бөтен төбәкләрендә язылырга мөмкин. Индексы – 54149.*

## Сөйгән сөелер

Бер кеше башка бер авылда яшәгән дин кардәшенең хәлен белер өчен юлга чыга. Аллаһы Тәгалә аның юлына кеше сурәтендә бер фәрештәне җибәрә. Ул исә теге кешенең каршысына очрап:

– Кая юл тотасың? - дип сорый.

– Фәлән авылда яшәгән дин кардәшемнең хәлен белер өчен барам, - дип җавап кайтара юлчы.

Фәрештә сорау алуын дәвам итеп:

– Синең аңа карата берәр дөнья йомышың бармы? – дип сорый.

– Минем аңа карата бернинди йомышым да юк. Мин аны Аллаһы Тәгалә өчен сөям, шуның өчен аның хәлен белергә янына барам, - ди фәрештәгә каршы теге кеше.

Кеше сурәтен алган фәрештә үзенең кем икәнлеген ачыклап:

– Мин синең яныңа Аллаһ тарафыннан җибәрелгән бер илчемен. Ул сиңа: "Аллаһы Тәгалә ризалыгы өчен ул кешене сөйгәнең өчен Аллаһы Тәгалә сине дә сөя, дип әйтергә боерды", - ди.

**("Бәхетлелеләрнең серләре" китабыннан)**

**Нәшире**
**Иршат Гыйльметдин улы**
**ШӘЙХАТТАР**

**Баш мөхәррир**
**Айгөл Абдуллина**

**Тел.:** (8552) 70-51-09
**Факс:** (8552) 70-51-45

* * *

**Оештыручылары:**
Үзәкләшкән дини оешма – Татарстан җөмһүрияте мөселманнары Диния нәзарәте, "Ислам нуры" дини эшмәкәрлек Үзәге

Газета мәкаләләрен күчереп басканда аларның "Ислам нуры"ннан алынганын күрсәтү мәҗбүри.

Редакциягә килгән язмалар игътибар белән өйрәнелә, рецензияләнә. Хатлар газетага әзерләнгәндә авторларның стиле саклана.

**Хатларны 423802, Чаллы Үзәк ур., 72 адресы буенча юллау кирәк.**

**Электрон хатлар өчен:**
**e-mail: islamnury@mail.ru**

Мөселманнар арасын бозуга, үзара каршылыкларга китерергә мөмкин булган хатлар, шикаятьләр газетада басылмый.

Дин-шәригать мәсьәләләренә кагылышлы язмалар, укучы сораулары Татарстан Диния нәзарәтенең баш казые, Чаллы төбәге мөхтәсибәтенең гыйльми Советы тарафыннан өйрәнелә һәм аларга җавап бирелә.

Россия Федерациясе матбугат, телерадиотапшырулар һәм массакүләм коммуникацияләр Министрлыгының Идел буе төбәкара территориаль идарәсендә ПИ № 7-0997 саны белән 2001 елның 15 ноябрендә теркәлде.

"Роспечать" агентлыгы каталогына кертелгән, язылу ел әйләнәсендә Россия Федерациясе буенча алып барыла.

Айга ике мәртәбә чыга.

**Тиражы 1100.**

**Индексы 54149**

* * *

Хөрмәтле укучыбыз!

Газетабызны укып чыккач, аны туганнарыгызга, танышларыгызга, яки башка мөселманнарга тапшырсагыз иде. "Ислам нуры"ның һәр саны кулдан-кулга күчеп динебезне таратырга ярдәм итсә иде. Әмин.

Шулай ук укучыларыбыз, Коръән аятьләре язылу сәбәпле, газетаны кирәкмәгән урыннарга ташлаудан сакланырлар дип ышанабыз.

* * *

Газета компьютерда җыелды, офсет ысулы белән "Ислам нуры" басмаханәсендә басылды.

Нәшир һәм редакция адресы:
**423802, Яр Чаллы,**
**Үзәк урамы, 72**

**Басарга кул куелды:**
**график буенча**
**28 ноябрь 16 сәг.**
**фактта 28 ноябрь 16 сәг.**

**Бәясе ирекле**